ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«20» декабрь 2021 ел № 419

Әгерҗе муниципаль районында җир кишәрлекләрен арендалау шартнамәсен төзүгә хокукны сату буенча ачык аукцион уздыру турында

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы территориясендә урнашкан җир ресурсларыннан нәтиҗәле файдалану максатларында, Россия Федерациясе Җир кодексының 39.11, 39.12 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Торак пунктларның җирләре составыннан җир кишәрлекләрен арендалау шартнамәсен төзүгә хокукны сату буенча аукцион үткәрергә һәм аукционга җир кишәрлекләре бирергә.
2. Аукцион комиссия составын расларга (1 нче кушымта).
3. Әгерҗе муниципаль районында аукционда җир кишәрлекләрен арендалау шартнамәсен төзүгә хокук сату өчен куела торган җир кишәрлекләренең исемлеген, бәяләү бәясе күләмен, сату өчен куела торган җир кишәрлегенең бәясен арттыру күләмен (Аукцион адымын) расларга (2 нче кушымта).
4. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (http://www.agryz.tatarstan.ru) һәм торглар үткәрү турында мәгълүмат урнаштыру өчен Россия Федерациясенең рәсми сайтында (https://torgi.gov.ru) җир кишәрлекләрен арендалау шартнамәсе төзүгә хокукны сату буенча ачык аукцион уздыру турында хәбәр урнаштырырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

**Җитәкчесе** **А.Э.Акбашев**

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Башкарма комитетының
20.12.2021 № 419
карарына 1 нче кушымта

**Аукцион комиссия составы**

1. Артур Эльфатович Акбашев - комиссия рәисе, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе;
2. Поносов Эдуард Александрович - Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының комиссия рәисе урынбасары, мөлкәти һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе (килештерү буенча);

**Комиссия әгъзалары:**

3. Лукшин Павел Алексеевич - Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының мөлкәти һәм җир мөнәсәбәтләре палаталарын тикшереп тору һәм исәпкә алу бүлеге башлыгы (килештерү буенча);
4. Андреева Ирина Евгеньевна - Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе урынбасары (килештерү буенча);
5. Вәлиев Руслан Рамил улы - Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе (килештерү буенча).

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Башкарма комитетының
20.12.2021 № 419
карарына 2 нче кушымта

**Әгерҗе муниципаль районында аукционда җир кишәрлекләрен арендалау шартнамәсен төзүгә хокук сату өчен куела торган җир кишәрлекләренең исемлеге, бәяләү бәясе күләме, сату өчен куела торган җир кишәрлегенең бәясен арттыру күләме (Аукцион адымы)**

| № | Урнашу урыны, җир кишәрлегенең мәйданы, кадастр номеры, аукцион үткәрү өчен нигез, капиталь төзелеш объектының максималь һәм (яки) рөхсәт ителгән минималь рөхсәт ителгән параметрлары, капиталь төзелеш объектын инженер-техник тәэмин итү челтәрләренә тоташтыруның (технологик тоташтыру) техник шартлары һәм аларның гамәлдә булу вакыты, тоташтыру (технологик тоташтыру) өчен түләү турында мәгълүмат | Рөхсәт ителгән куллану | Аренда срогы | Еллык аренда түләвенең башлангыч күләме, сум. | Аукцион адымы (башлангыч бәядән 3%), сум | Беренчел кертем (башлангыч бәядән 20%), сум |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| 1 | Татарстан Республикасы, Әгерҗе муниципаль районы, Кадыбаш авыл җирлеге Кадастр номеры - 16:01:130403:309 | Авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен | 49 ел | 109976,04 | 3299,28 | 21995,21 |
| 2 | Татарстан Республикасы, Әгерҗе муниципаль районы, Кадыбаш авыл җирлеге Кадастр номеры - 16:01:130403:98 | Авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен | 49 ел | 63311,32 | 1899,34 | 12662,26 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | Татарстан Республикасы, Әгерҗе муниципаль районы, Кодаш авыл җирлеге Кадастр номеры - 16:01:040604:283 | Авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен | 8 ел | 88260,35 | 2647,81 | 17652,07 |
| | Татарстан Республикасы, Әгерҗе муниципаль районы, Салагыш авыл җирлеге Кадастр номеры – 16:01:190702:90 | Авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен | 49 ел | 62890,50 | 1886,71 | 12578,1 |